РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

08.02.2019

№ 24-п

Линия объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты хакында фикер алышу буенча җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 ел, 21 ноябрь, 94нче карары белән расланган "Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмә"гә яраклы рәвештә, "ГАЗПРОЕКТИНЖИНИРИНГ" бүлендек ачык акционерлык җәмгыятенең 21.12.2018 ел 24090/81 номерлы гаризасын караганнан соң һәм халыкның җәмәгать тыңлаулары аша Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының "Линия объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проектын эшләү турында" 13.11.2018 ел 1652-п номерлы карарына туры китереп әзерләнгән линия объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегендә "Шәмәрдән магистраль газүткәргеләр линия-җитештерү идарәсе "Арча" компрессорлар станциясенең газүткәргеләрне тоташтыру узелларын саклау буенча инженерлык-техник чараларын җиһазлау" проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты - 2019 елның 12 мартында, 9.00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Эзмә авыл җирлеге, Эзмә авылы, Школьная урамы, 5а йорты, Эзмә авыл мәдәният йорты бинасы.

2.3. Фикер алыша торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашуга гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г. Закиров урамы, 52 нче йорт, 105 каб. адресы буенча тапшырыла ала.

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашуга гаризалар бирү срогы – 2019 елның 7 марты.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә:

– 2019 елның 12 мартына кадәр әлеге карарны биләмәне планлаштыру һәм ызанлау документлары белән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында, Саба муниципаль районы рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) “Җәмәгать тыңлаулары” бүлегендә бастырып чыгарырга;

– җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында “Җәмәгать тыңлаулары” бүлегендә бастырып чыгарырга;

4. Әлеге карарның рәсми төстә басылып чыккан көненнән үз көченә керүен билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов